| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**02.06.2017** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1621** |

Зеленодольск шәһәренең аз катлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты коммуналь калдыклар чыгару турында

«Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2010 елның 27 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль закон , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советының 2014 елның 26 маендагы 251 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән, чисталыкны тәэмин итү, йогышлы авырулар таралуны кисәтү һәм экологик хәлне яхшырту, шулай ук уңайлы яшәү шартлары булдыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1.1. милекнең оештыру-хокукый формасына карамастан, оешмаларга, шулай ук Зеленодольск шәһәренең аз катлы төзелеш территориясеннән чүп-чар чыгару буенча хезмәт күрсәтүче индивидуаль эшмәкәрләргә югарыда күрсәтелгән территориядә яшәүче кулланучылар белән шартнамәләр төзергә;

шартнамә төзегәндә, каты коммуналь калдыкларны җыю, чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе, контейнер мәйданчыкларын җыештыруны һәм контейнерларны һәм контейнер мәйданчыкларын карап тотуны исәпкә алып, бер кешедән аена 59,90 сумнан артык булмаган күләмдә билгеләргә;

1.3. оешмаларга, аларның оештыру-хокукый формасына карамастан, шулай ук Зеленодольск шәһәренең аз катлы шәхси торак төзелеше территориясеннән чүп чыгару буенча хезмәт күрсәтүче индивидуаль эшмәкәрләргә, аз катлы шәхси төзелеш территориясендә яшәүче кулланучыларга үз эшләрендә, Зеленодольск шәһәре Советының 2014 елның 26 маендагы 251 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә таянырга.

2. Әлеге карар 2017 елның 01 июленнән үз көченә керә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин